**МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ**

---

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.02.2019 Казан шәһәре № 76 од

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының аерым боерыкларының үз көчләрен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты турында» 2018 елның 28 июнендәге ПУ-462 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты мәсьәләләре» 2018 елның 12 июлендәге 565 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 18 августындагы 409 номерлы карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы структурасын раслау турында» 2018 елның 12 июлендәге 566 номерлы карары нигезендә

**БОЕРЫК БИРӘМ:**

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Региональ (республика) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 14 февралендәге 132 од номерлы;

«Региональ (республика) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга йөкләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 14 февралендәге 133 од номерлы;

«Региональ (республика) әһәмияттәге мәдәни мирас объектын, ачыкланган мәдәни мирас объектын саклау эшләрен башкаруга проект документациясен килештерү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2017 елның 14 февралендәге 134 од номерлы.

**Министр** **Ф.Х. Әюпова**